Татарстан яшьләре

№17

(8817)

ШИМБӘ

7 август, 1993 ел

Бәясе килешү буенча.

* ЯШЬЛӘРНЕҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ * 1920 ЕЛНЫҢ 22 ГЫЙНВАРЫННАН БИРЛЕ ЧЫГА *

Яңа партияләр оеша

димәк, яңа сайлаулар якынлаша

Татарстанда тагын бер партия оешырга тора. Исеменә һәм аны оештырырга йөрүчеләрнең исемлегенә караганда, партия уңга яки сулга хаермыйча гына үзәктән бару сәясәтен алып барачак. Җыелышка килгән халыкның күпчелеген халык депутатлары, дәүләт органнары вәкилләре, иҗат интеллигенциясе, галимнәр, эшкуарлар, җәмәгать эшлеклеләре һәм журналистлар тәшкил иткәнлектән, оештыру комитетына да танылган сәясәтчеләр (Р.Хәкимов, А.Колесник), галимнәр (М.Рохицкий, М.Шабаев), язучылар (Т.Миңнуллин, Р.Харис), министр (А.Щеповских) һәм журналистлар (Р.Ратникова) сайланган.

Партия төзү өчен җәелдерелгән хәрәкәт бүген үзенең төп максаты итеп түбәндәгеләрне билгеле: тынычлык һәм килешеп яшәүне хуплау, республика халкының тормышын яхшыртуны тәэмин иткән катнаш типтагы базар икътисадын булдыру, җинаятьчелек белән көрәшне көчәйтү, Татарстанның мөстәкыйльлеге нигезендә демократияне үстерү, дөнья бердәмлегенә керүгә юл ачачак дәүләтчелекне ныгыту. Әйтелгәннәрдән аңлашылганча, партия бүген Президент һәм аның командасы, парламент һәм хөкүмәт алып барган эшне үз җилкәсенә алырга җыена. Димәк, "Бердәмлек һәм прогресс" партиясе сан ягыннан да иң зурлардан булачак дип фараз итәргә мөмкин.

Соңгы вакытта иҗтимагый оешмаларның *һәм сәяси партияләрнең* яңадан хәрәкәткә килүен аңлатуы кыен түгел: Татарстанда яңа Президент һәм парламент сайлауларына әзерлек эше башлана. Ә ул сайлауларның без белгән бер генә сайлауларга да охшамаганлыгын чамалавы авыр түгел. Яңа оешачак "Бердәмлек һәм прогресс" исә бүген үзенең үзәктән баруы белән абруй казанган Президент сәясәтен байрак итеп ала.



Рамил Хәйретдинов Лениногорск районының Куйбышев исемендәге колхозында иң яшь тракторчыларның берсе санала. Яшь булса да сыната торган егетләрдән түгел ул. Нинди генә эш кушсалар да, Рамил аны җиренә җиткереп, яхшы сыйфатлы итеп башкара. Яшь егет быелгы урып-җыю чорында да сынатырга уйламый.

Рәсемдә: Лениногорск районы, Куйбышев исемендәге колхозның иң яшь тракторчысы Рамил Хәйретдинов.

А.БИКТИМЕРОВ фотосы.



Яхшы тикшерүче җәяү йөрмәс

Республика Эчке эшләр министрлыгы моңарчы булмаган бәйге үткәрергә җыена. "Татарстанның иң яхшы тикшерүчесе" дигән исемне алу өчен барачак конкурска нибары 21 тикшерүче генә катнашачак. МВД, КГБ һәм Прокуратурада эшләүче иң-иң "эзтабарлар" арасында җиңүче дип табылган хезмәткәргә мактаулы исем белән бергә соңгы модель "Жигули" машинасы да биреләчәк. Икенче бүләк - "Ока" автомобиле, ә өченче урын алучыга "Хитачи" видеомагнитофоны.

Кемгә - солых, кемгә - сугыш

Үзләрен "Рабочий союз" дип атаучы бер төркем ур-ра патриотлар Татарстан җитәкчелегенә мөрәҗәгать белән чыкты. Тыныч Казанда ягып өйрәтергә яратучылар Таҗикстанга хәрби ярдәм күрсәтергә, Татарстан акчасына доброволецлардан хәрби подразделение тупларга чакыралар. *Менә шулай.* Фәндәс Сафиуллин шикелле фидакарьләребез ут эченә барып таҗик халкын: "Татарлар сезнең белән сугышмый һәм сугышмаячак та", - дип ышандыра-ышандыра Таҗикстандагы күпсанлы татарларны кайгыртып йөрсә, Казандагы "рабочий"лар икенче әфган сугышына сусаганлыкларын яшермиләр. Белеп әйтә икән халык: әрә белми әргән эт өстенә бүре китерә.

Киңәшле эш таркалмый?

14 август көнне иртәнге 11 сәгатьтә Чаллы иҗтимагый үзәгендә Зур милли киңәшмә үткәреләчәк. Бу турыда хәбәр иткән Н.Сафин: "Мәҗлестә татар милли хәрәкәте үзенең сәясәтендә яңа баскычка күтәреләчәк, - дип белдерде. - Шуның өчен анда урыннардагы ТИҮ җитәкчеләре һәм һәр төбәктән 3-4 делегат чакырыла". Мәҗлестә әле шушы көннәрдә генә иреккә чыгарылган БТИҮ рәисе Зиннур Әһлиуллинның да катнашуы соңгы вакытта туктаусыз барган бәхәсләргә ачыклык кертер дип көтелә.

Төрки яшьләр берләшә

"Идел" яшьләр лагеренда кичә I Төрки яшьләр көннәрен ачу тантанасы булды. 16 августка кадәр дәвам итәчәк яшьләр җыенында катнашучылар Казанда Алтын Урда оешуга 750 ел тулуын бәйрәм итәчәкләр, шәһре Болгарга сәяхәт кылачаклар, башкаланың истәлекле урыннары белән танышачаклар. Лагерьда шулай ук Төрки яшьләр ассоциациясенең IV Корылтаен үткәрү дә күздә тотыла.

Министрлар килеште

Татарстан һәм Мари-Эл Мәгариф министрлыклары арасында килешүгә кул куелды. Министрлыклар ике республикадагы татар һәм мари балаларын ана телләрендә укыту бурычын үз өсләренә алалар. Килешүдә шулай ук тәҗрибә алмашу, вузларда квота булдыру һәм башка төрле хезмәттәшлек итү мәсьәләләре дә каралган. Татарстанның Башкортостан, Удмуртия һәм Чувашия белән андый килешүләре төзелгән иде инде.

Базар хикмәтләре

Безнең тормыш шушы саннарда

Татарстанның статистика буенча дәүләт комитеты безнең үткән ярты еллык тормышыбызга нәтиҗә ясады.

Анда китерелгән саннарга караганда, быелның алты ае дәвамында куллану бәяләре уртача 3,2 мәртәбәгә арткан. Ә аерым алганда, промышленность бәяләре - 2,9, хезмәт күрсәткән өчен алына торган бәяләр 6,2 мәртәбәгә күтәрелгән. Ит июньдә май ае белән чагыштырганда 60,9, яшелчә - 78,8, ярма әйберләре 57 процентка кыйммәтрәккә сатылган.

Аның каравы, статистлар безнең кулга кергән акчаның күләме дә бик күпкә арткан дип исәплиләр. Алар җитештерү өлкәсендә эшләүчеләрнең июнь аендагы уртача хезмәт хакы - 40,9 мең сум, төзүчеләрнеке - 62,9 мең сум, авыл хуҗалыгында эшләүчеләрнеке - 26,4 мең сум, транспортчыларныкы - 52,3 мең сум, мәдәният һәм фән эшлеклеләренеке - 26,1-31,5 мең сум, халык мәгарифе хезмәткәрләренеке 35,1 мең сум булды дип раслыйлар. Шулай итеп, без үткән елның июнь ае белән чагыштырганда быелгы июньдә 14,2 мәртәбә күбрәк акча алганбыз. Ә инде сезнең исәп статистика исәбенә туры килми икән - аптырамагыз: статистлар күршеләрегезнең зур акчасыннан сезгә дә "өлеш чыгаралар". Нәкъ шул рәвешле Татарстанда яшәүче һәр кеше башына июнь аенда 26 мең сум акча килеп чыккан. Ә бездә ачтан үлмәс өчен бүген нибары 9024,5 сум акча кирәк икән.

Статистлар китергән тагын берничә күңелле һәм күңелсез саннарга тукталып китик.

Күңеллеләренә азык-төлек товарлары җитештерүнең үткән елгы яртыеллыктагыдан - 20,3 процентка, торак мәйданы төзү - 3,8 процентка, промышленность әйберләре эшләп чыгару бәя ягыннан 6,1 мәртәбәгә артуын кертергә була. Ә күңелсезләре - үлем-җитем арткан, туучылар саны кимегән, эшсезләр саны 13,1 меңгә җиткән, аракыны күбрәк эчә башлаганбыз.

"Татарфильм" каскадерлары

"Татарфильм" киностудиясе оештырылуы һәм Болгар турында беренче тарихи фильм төшерелә башлаячагы турында хәбәр иткән идек инде. Танылган кинорежиссер Булат Мансуров төшерәчәк кинолентада берсеннән-берсе катлаулырак трюклар, кул сугышлары һәм көрәш мизгелләре күп булганлыктан, үзеннән-үзе каскадерлар булдыру проблемасы да килеп баскан. Хәер, киностудия булгач, аның каскадерлары да булырга тиеш инде. Шунлыктан Казанда каскадерлар әзерләү студиясе эшли башлый. Бу - Идел буе регионында мондый бердәнбер мәктәп булачак. Курку белмәс кыю һәм җитез ир-егетләрне шулай ук танылган артист-каскадер Еркен Сарсембаев өйрәтәчәк. Студиягә кабул итү август аенда башлана.



Үпкә урынына - бавыр

Үпкәсе авыру пациент операция вакытында ярты бавырын "югалта". Бу хәл Япониянең Кумамато муниципаль госпиталендә була. Бу хәлнең җаваплысы - операциягә керергә тиешле ике авыру салынган арбаны бутаган медперсонал. Хирург бавырның яртысын кисеп алгач кына аның сәламәт булуына игътибар итә. Шулай да ул сәламәт үпкәне кисәргә җыенган коллегасын кисәтергә өлгерә. Шуннан соң, ниһаять, ике авыруга да тиешле операцияне ясыйлар. Ике пациентка да китерелгән зыян өчен компенсация түләнәчәк.

"Рубль" - грузин дошманы

Грузиядә бердәнбер акча берәмлеге - грузин купоны гына әйләнештә йөри башлады. "Рубль"не куллану өчен административ чаралар каралган. Болар - эштән куылу, булган "рубль"не һәм башка төрле акчаны конфискацияләү.

Ә Абхазиядә, парламент күрсәтмәсе нигезендә, "рубль" әйләнештә кала.

Сыер икәнсең - нәзберек булма

Яһүд автономияле өлкәсе фермерларына озакламый Кубадан зебу сыерлары кайтарылачак. Галимнәр фикеренчә, бу бик куе сөтле сыерлар кырыс климатка тиз ияләшергә тиешләр икән. Голланд токымлы сыерлар, сөтле булсалар да, өлкәдә зур уңыш казана алмаганнар. Белгечләр сүзе белән әйткәндә, артык нәзберек булып чыкканнар.

Сугыштан соңгы авыр еллар иде. Без, өч кеше, бер ятим карчыкның үтенече белән өмә ясап, аның йорт түбәсен яптык - ул вакытта ничек булсын инде - салам белән. Эш беткәч, карчык хәленнән килгәнчә табын әзерләде. Табында, сүз иярә сүз чыгып, мин "агитация" белән шөгыльләндем:

- Без бүген изге бер эш эшләдек. Кулы, аягы исән, саусәламәт кешегә моның бер кыенлыгы да юк бит. Беребезнең дә бер җире кителмәде. Уйлап карыйк әле: дөньяда тома сукырлар, кулсыз яки аяксыз гарипләр бар. Әгәр шулардан: кодрәт белән сине күзле яки аяклы итсәм, елына бер генә көн булса да гарипләргә буш-

Савап турында оныттык

ка эшләр идеңме дип сорасаң, алар: бер түгел, бер ай эшләргә риза, диячәк. Шулай булгач, әйдәгез иртәгә килеп әбинең чоланын да төзәтеп бирик.

Минем сүзләрем бушка китмәде. Икенче көнне өчебез дә, кем такта, кем киртә, кем кадак алып килеп әбинең чоланын төзәтеп куйдык.

Узганнан тагын бер мисал китерәсе килә. Шул ук сугыштан соңгы авыр елларда безнең авылда Исламгулов Зиязетдин агай карар кешесе булмаган ике карчыкны үз өенә алып, алар үлгәнче асрап, тәрбияләп күмде. Уйлап карагыз әле: кемнең кулыннан килә бу эш бүген? Киресенчә, көннән көн катырак бөгырьле була барабыз, чит кортканы асрау түгел, үз ата-анасын куып чыгарган кешеләр бар. Кайберәүләр мөмкинлек юкка сылтар имеш, үз дөньясын кетәргә дә авыр, кая ул кеше кайгысы. Колхоз эшеннән соң үз сыерын җигеп урманнан утын алып кайтып, шуны сатып көн күргән Зиязетдинның мөмкинлеге зур булганмы? Бүген 3-4 миллион сумга машина алган кешенең мөмкинлеге Зиязетдин мөмкинлегеннән кимрәкме?

СССР таркалды. Аның яңадан оешуына өмет бик аз. Кайберәүләр моңа сөенсә, акыллы кешеләребез моның зур фаҗига булуын аңлый. СССР республикаларының бердәм, дус яшәгән елларын хәтергә төшерик. Башта Ашхабадта, соңрак Ташкентта көчле җир тетрәү булды. Шунда бөтен ил ярдәм кулын сузып, кеше көче, техника, төзү материаллары белән ярдәм итеп, бу шәһәрләрне кыска гына вакыт эчендә аякка бастырдылар. Бу фактларны тарихтан сызып ташлап булмый.

Ә бүген ничек? Бүген шәфкатьлелек, миһербанлылык күзгә күренеп кими, бетә бара. Бүгенге мәктәп укытучыларына да үпкә белдерәсе килә. Сугыш һәм сугыштан соңгы елларда мәктәпләрдә яшь тимурчылар отрядлары оештырыла иде. Алар ярдәмгә мохтаҗ картларга, гарипләргә бик күп ярдәм иттеләр. Нигә соң бүген бу эш онытылды? Нигә без ярдәмне Мәскәүдән, Казаннан, собестан көтеп ятабыз? Мин мисалга китергән Зиязетдин агай кебек чит карчыкларны асрауга алу кебек үк олы эшләр тәкъдим итмим, аның өчен күңел җылысы, көчле ихтыяр кирәк. Ләкин күршедәге карт-карчыкка көненә бер көянтә су китерү хәлдән килмәслек эш түгел. Буш вакытын кая куярга белми интеккән егетләргә бер гарипнең утынын ярып бирү дә һич кыен булмас иде. Аракы яки акча өмет итеп түгел, әлбәттә, савап өчен!

Соңгы елларда дингә караш уңай якка үзгәргәндәй тоела. Радиодан, телевизордан - вәгазьләр ишетелә. Бу бик яхшы. Ләкин әлегә бу вәгазьләр бер колактан керә, икенчесеннән чыга кебек - нәтиҗәсе күренми.

М.ГАЛИМОВ.
Башкортостан,
Туймазы районы.

Халыкның хәтере яхшы...

Русия телевидениесеннән Зиннур Әһлиуллинны кулга алулары турында хәбәр иттеләр. Без ирем белән тетрәнеп киттек. Янәсе, ул митингта М.Шәймиевкә физик куркыту белән янаган, өеннән корал тапканнар, имеш. Без моңа ышанмыйбыз. Зиннур Әһлиуллин халкыбызның азатлыгы өчен көрәшә. Кайбер җитәкчеләргә, урыс шовинистларына бу ошамый. Төрле сылтаулар табып, халык азатлыгы өчен көрәшкән, халкыбызга матди ярдәм күрсәткән изге кешеләребезне йә кулга ала, йә үтерә башладылар. Моңа мисаллар җитәрлек: Татарстанда, Казанда, Екатеринбургта, Новосибирскида һ.б. шәһәрләрдә халкыбызга ярдәм күрсәткән эшкуар-коммерсантларны үтерделәр инде. Чаллыда Кашаповлар кибетенә ОМОНнар тарафыннан һөҗүм ясау шул явызлыкларны раслый. Халыкның хәтере бик яхшы аның, ул яхшылыкны да онытмый, халыкка каршы эшләгән явызлыкны да.

Нәзирә МЕДВЕДЕВА.
Мәскәү.

Сәләтлеләр югалмасын иде

Халык табибы Сания Мингалиева "Т.Я."ны өшкергәннән соң газетага рәхмәтләр явып кына торды. Бу куанычлы хәл. Бар бит көчле биотокка ия кешеләр. Менә шундыйларның берсе Чаллы шәһәрендә яши. Ул Гөлнәфидә ханым. Экстрасенсларга шикләнебрәк карасам да, Гөлнәфидә белән якыннанрак танышкач, ышану гына түгел, аңа сокланып кайттым.

Барып кергәч, Гөлнәфидә кай җирең авырта дип сорап тормый, бармаклары белән чирне үзе эзләп таба һәм массаж ясап, учларыннан җылы энергия җибәреп дәвалый да башлый. Күз тигәнне, бозыкны да күрә һәм бетерә. 7 сеанстан соң үземне яңадан тугандай хис иттем, остеохондроз, ашказаны, баш авыртуларым бетте. Баламның умыртка сөяге төзәйде. Гомумән, аңа килүчеләр сихәтләнеп, рәхмәт әйтеп китәләр. Башка экстрасенслардан аермалы буларак, Гөлнәфидә үзенчәлекле рәсемнәр ясый, йөрәккә ятышлы, матур шигырьләр дә яза икән. Ул шигъри юлларны тыңлап утыруы үзе бер дәва. Җаннарың тынычланып, рәхәтләнеп китәсең. "Минем махсус белемем юк, элек мондый шигырьләр дә язганым булмады, - ди Гөлнәфидә. - Авыру балам белән Фарис Галләм сеансларына йөргәннән соң барлыкка килде бу үзгәрешләр. Балам да терелде. Ә иҗади көч миңа Үзбәкстан ягыннан Батыр Закиров җаны аша килә. Ул халык җырчысы булган. Аның каберенә чәчәкләр өзелмәскә тиеш. Үзем дә барып каберен зиярәт кылып кайтырга хыялланып яшим. Чөнки әлегәчә җавап таба алмыйм, нигә миңа Үзбәкстаннан шундый көч килә? Безгә - мөселманнарга берләшергә, акыл белән эш итәргә кирәк. Шунда гына барсы да ачыкланыр, кара көчләр дә юкка чыгар. Башка милләт халкын яманламыйм, диннәрен үзләренчә тотсыннар. Әмма иң дөресе, иң өстене - Ислам дине. Чөнки без сынга, тәрегә түгел, ә Аллаһы Тәгаләнең турыдан-туры үзенә кулларыбызны күтәреп дога кылабыз!"

Минем әйтәсе килгән сүзем шул. Арабыздан кызыклы, илаһи көчкә ия кешеләребезне күреп алсыннар, кирәк вакытта һәрдаим ярдәм итеп, алга барырга ирек куйсыннар иде.

Ихтирам белән, Мәйсәрә ХӘММӘДИЕВА.
Чаллы.

Утырып калмаска иде

Мин гади бер Казан кызы. Матур июнь кичендә минем күзем Фәритнең "Күңелемдә - яз сагышы" дигән хатында тукталды. Шушы хат минем күңелемдә дә сагыш уятты, чөнки, чынлап та, хәзерге вакытта саф күңелле, оялчан, чиста җанлы яшьләргә очрашып, дуслашырга бер шартлар да юк. Дискотекага барсаң, анда ямьсез күренешләргә тап буласың, киного берүзең генә барасы килми, танышу кичләре беркайда да үткәрелми. Шулай өйдә утырып каласың. Фәритнең шушындый матур әдәби татар телендә язган хаты мине бик дулкынландырды. Мин дә 19 яшькә җитеп, егетләр белән шаяртып йөргәнем булмады. Минем кебек кызларның яхшы, саф күңелле, чын егетләр белән дуслашасы килә. Рәхмәт сиңа, Фәрит, хәзерге заманда шушындый булып калганың өчен. Мин дә, синең кебек, чын, пакь сөюгә, мәхәббәткә ышанам. Әгәр син риза булсаң, мин синең белән танышыр идем.

ДИЛӘРӘ.
Адресым редакциядә.

Татарның акылы төштән соң...

"Татарстан яшьләре"ндә "Читтән килгән афәт" дигән мәкаләне укыгач, төн йокыларым качты. Анда чукындыру белән шөгыльләнүче имансызлар турында язылган иде. Ул газетаны укыганым өчен үкендем, чөнки ашавым да аш булмый башлады. Радиодан, әнә, Илһам Шакиров җырлый: "Уян, татар" ди. Без уянганчы, башкалар әллә кайчан торып, үз пычракларын эшләп йөриләр түгелме соң? Алар 7-8 мең татарны чукындырып өлгергәннәр икән, бу - уяну түгел, озын йокыга китү буладыр. Нишләп әле моны дин әһелләре белмәделәр икән? "Татарның акылы төштән соң" дигән сүзләрне ишеткәнем бар. Болай да татар халкы урыслардан азрак, хәзер бу чукынучылар татар дип саналамы соң? Бу эш хөкүмәт башлыкларының ризалыгыннан башка эшләнгәнме?

Әкъмимә ЗАРИПОВА.
Пермь өлкәсе.

Белдегезме?!

Е.КАНАЕВ фотосы.

* Кайтаваз * Кайтаваз * Кайтаваз * Кайтаваз * Кайтаваз * Кайтаваз * Кайтаваз *

Татар ник таралган?

- Язучы Мөхәммәт Мәһдиевнең "Түрәләр" исемле язмасын укыгач, кайбер фикерләремне язарга булдым. 1941-45 елгы сугыш һәм сугыштан соң еллардагы хәлләрне үз күзем белән күреп белгәнгә, язмадагы юлларны укыгач, алар кабат хәтерне яңартты, йөрәкне өрнетте.

Колхозда көне-төне эшләгән өчен хезмәт көне генә яздылар, бер грамм да ашлык бирмиләр иде. Урып-җыю башлануга район түрәләре барлык ашлыкны дәүләткә тапшырттылар. Халык ничек яшәргә тиеш булгандыр, анысы берәүне дә кызыксындырмады. Балалар, карчыклар качып-посып кына комбайн урганнан соң калган эрыш, бодай башакларын җыялар иде. Чөнки авыл куштаннары җыйган башакларны күреп калсалар, басудан куып кайтардылар, башак кырда калып череса череде, әмма кешегә генә булмады. Шушы принцип хәзергәчә сакланып килә.

Дәүләткә бөтен ашлыкны тапшырганнан соң, яз көне 15 чакрым ерaклыктагы "Каратун" станциясеннән чәчүлек орлыкны җилкәләренә күтәреп ташырлар иде авылдашларым. Хуҗалыкта терлек-туар, кошкорт булмаса да, һәрбер кешене дәүләткә ит, сөт, йомырка түләргә мәҗбүр иттеләр. Ә менә йонны сарык саны исәбеннән түләттеләр. Хуҗалыктагы сарыкларның, бәраннәрнең исәбен алалар да, йон түләүне сарыкка да, бәрәнгә дә бер күләмдә билгеләләр. Әнием еш кына дәү әниемнең көйләп сөйләгән сүзләрен искә төшерә: "Әй Микулай, Микулай, ике сыер саудырдың; совет власте килде дә кәҗәсез дә калдырды". Сигез бала үстергән дәү әнием бу сүзләрне җиңел тормыштан әйтмәгәндер, билгеле.

Сугыштан соңгы елларда халыкның авыр тормышына карамастан, сигезенче сыйныфтан башлап укыган өчен акча түләттеләр, вакытында түләмәсәң, яхшы укысаң да мәктәптән чыгаралар иде. Акча түләргә мөмкинлеге булмаган байтак кына балалар укуларын дәвам итә алмаганнардыр, мөгаен. Туган авылым Әнәле авылыннан (Апас районы) ул елларда урта мәктәпне Галәветдин Гыймадиев һәм мин тәмамладык, аннары югары уку йортында укып чыктык. Авыл кешесен әнә шулай матди яктан да, мораль яктан да кыстылар, рәнҗеттеләр. Авыр тормышка чыдый алмыйча, милләттәшләребез - авылдашларым Урта Азиягә, Украинадагы шахталарга, күрше Русиянең төрле өлкәләренә һәм чит илләргә бәхет эзләп киттеләр, туган җирләреннән аерылырга мәҗбүр булдылар. Шуңа күрә дә бүген татарның күбесе үз иленнән читтә яши.

Сәгъдулла ШӘЙХУЛЛА.
Казан.



ДҮШӘМБЕ

9 август

ТАТАРСТАН

7.00 "Чулпан".
17.15 Эфирда - компьютер информациясе.
17.25 "Мио, минем Мио".
19.00 Татарстан.
19.35 Республика: сәяси көндәлек.
20.05 Әлли-бәлли-бәү.
20.15 Хөрмәтле редакция.
21.05 "Сеньорита".

ЭФИР

10.00 Супер чэннел.
10.30 "Маниту". Нәфис фильм.
12.10 Супер чэннел.
17.00 Мультфильмнар.
17.30 Супер чэннел.
19.30 Анонслар.
19.45 Шәһәр.
20.00 Телетекст.
20.15 Бизнес-фарватер.
20.25 "Уолл Стрит". Нәфис фильм.
22.30 Шәһәр.

ОСТАНКИНО

6.00, 9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Яңалыклар.
6.20 Иртәнге гимнастика.
6.30 Иртә.
8.45 Фирма гарантия бирә.
9.20 "Му-му".
11.15 Тема.
12.20 Гол.
15.25 Телемикст.
16.10 Эш.
16.20 Мультфильм.
16.45 Прелюдия-кантата.
17.00 Епископ Василий.
17.15 Йолдыз сәгате.
18.25 Музыкаль мозаика.
18.45 Гол.
19.15 "Резонанс" студиясе.
19.45 "Биш кыз Парижда". 1 серия.
20.40 Тыныч йокы, нәниләр.
21.00 Яңалыклар.
21.40 Балет йолдызлары.
22.50 "Яңа студия".

РОССИЯ

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 Хәбәрләр.
8.20 Хезмәт биржасы.
8.30 Эшлекле кешеләр заманы.
9.00 Иртәнге концерт.
9.15 "Мәскәү сөйли".
10.00 Сабый теле белән.
10.30 Иске тасмалар.
11.00 Док.фильм.
12.10 "Ялгызларга тулай торак бирелә". Нәфис фильм.
13.40 Крестьян мәсьәләсе.
14.25 "Коралланган һәм бик куркыныч". Нәфис фильм.
16.00 Док.фильм.
16.30 Там-там яңалыклары.
16.45 Россиядә бизнес.
17.15 "Европа - Азия".
18.00 Россияне ничек үзгәртеп корырга?
18.45 Парламент сәгате.
19.45 Көн дә бәйрәм.
20.25 "Корапны талау". Нәфис фильм.
21.20 Мультфильм.
21.30 Манера.
22.00 Хакыйкать мизгеле.
23.20 Автомизгел.
23.25 Йолдызлар сөйли.
23.35 Динозавр булмаска.
23.50 Коткару-911.

СИШӘМБЕ

10 август

ТАТАРСТАН

7.00 "Чулпан".
18.10 Үз җырыбыз булсын әле.
18.25 ТР Президенты М.Шәймиев.
19.00 Татарстан.
19.35 Актуаль интервью.
20.05 Шигърият.
20.15 Әлли-бәлли-бәү.
20.25 Питрау бәйрәме.
21.05 "Сеньорита".

ЭФИР

9.45 Телетекст.
10.00 Шәһәр.
10.15 "Уолл Стрит".
12.15, 17.30 Спутник телевидениесе.
17.00 Мультфильмнар.
19.10 Видеомода.
19.35 Грация.
20.00 Камиллекнең үзе.
20.25 "Таш турында роман". Нәфис фильм.

ОСТАНКИНО

6.00, 9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 21.00 Яңалыклар.
6.20 Иртәнге гимнастика.
6.30 Иртә.
8.45 Фирма гарантия бирә.
9.20 Кара, тыңла...
9.40 Мультфильм.
9.50 "Мария".
10.35 Кеше һәм закон.
11.05 "Сары елга". 3 серия.
12.20 "Петров һәм Васечкин мажаралары". 1 серия.
13.25 Док.фильм.
13.55 "Спрут-3". 1 серия.
15.25 Эшлекле хәбәрче.
15.40 Конверсия һәм базар.
16.10 Блокнот.
16.15 Мультфильм.
16.40 Док.фильм.
17.00 Телефильм.
17.10 Стартинейджер.
17.50 Технодром.
18.25 "Хакимияттә кунакта". Татарстан Республикасы Президенты М.Шәймиев.
19.05 "Мария".
19.55 Тема.
20.40 Тыныч йокы, нәниләр.
21.40 "Останкино-93" хит-парады.
22.40 Шәхси мөлкәт әлифбасы.
23.00 "Пепси" стилендәге музыка. Джексоннар. Америка хыялы". 2 серия.
0.25 Рок-н-ролл.

РОССИЯ

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 Хәбәрләр.
8.20 Хезмәт биржасы.
8.30 Эшлекле кешеләр заманы.
9.00 Хакыйкать мизгеле.
12.00 "Үлем вонасы". Нәфис фильм.
13.25 Мультфильм.
13.40 Крестьян мәсьәләсе.
14.25 Ак карга.
15.10 Пианист Н.Петров.
16.05 Док.фильм.
16.30 Там-там яңалыклары.
16.45 "Яшел мәктәп".
17.15 Ничек яшисең, Уфа?
18.00 Әфәнделәр-иптәшләр.
18.45 Парламент сәгате.
19.45 Көн дә бәйрәм.
20.25 "Санта-Барбара".
21.15 "С.-Петербург" оркестры.
22.00 Ватаным.
22.30 "Грузин талашы".
23.20 Автомизгел.
23.25 Йолдызлар сөйли.
23.35 Телефильм.

ЧӘРШӘМБЕ

11 август

ТАТАРСТАН

7.00 "Чулпан".
18.05 Эфирда - компьютер информациясе.
18.15 Мультфильм.
18.40 Хәрәкәт куркынычсызлыгы өчен.
19.00 Татарстан.
19.35 Халык иҗаты.
20.05 Әлли-бәлли-бәү.
20.15 Язучы фикере. М.Мәһдиев.
20.50 "Сеньорита".

ЭФИР

10.00 Супер чэннел.
10.30 "Таш турында роман".
12.50, 17.30 Супер чэннел.
17.00 Мультфильм.
19.45 Шәһәр.
20.00 Телетекст.
20.15 Сәүдә каруселе.
20.45 Бизнес-фарватер.
20.55 "Мишень". Нәфис фильм.
22.50 Шәһәр.

ОСТАНКИНО

6.00, 9.00, 12.00, 18.00, 21.00 Яңалыклар.
6.20 Иртәнге гимнастика.
6.30 Фирма гарантия бирә.
9.20 Док.фильм.
9.40 "Мария".
10.30 Сәүдә күпере.
11.00 "Сары елга". 4 серия.
12.20 "Петров һәм Васечкин мажаралары". 2 серия.
13.30 Док.фильм.
13.50 "Спрут-3". 2 серия.
15.25 Телемикст.
16.10 Блокнот.
16.15 Мультфильм.
16.40 Телефильм.
17.00 700 клубы.
17.50 Технодром.
18.25 "Останкино" тәкъдим итә.
19.00 "Мария".
19.45 Миниатюра.
20.00 Кремль сәхнәсы артында.
20.40 Тыныч йокы, нәниләр.
21.40 Футбол. "Локомотив" (Н.-Новгород) - "Спартак" (Мәскәү).
22.30 Мода сихере.
23.00 Музыка фестивале.

РОССИЯ

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 Хәбәрләр.
8.20 Хезмәт биржасы.
8.30 Эшлекле кешеләр заманы.
9.00 Параллельләр.
9.15 Ватаным.
9.45 Грузин талашы.
10.10 Манера.
10.40 Йолдыз яңгыры.
12.00 "Санта Барбара".
12.50 Сәнгать мәйданы.
13.40 Крестьян мәсьәләсе.
14.25 "Сынган дага". Нәфис фильм.
15.45 Док.фильм.
16.15 Бизнес: яңа исемнәр.
16.30 Там-там яңалыклары.
16.45 Шәһәрчек.
17.15 Ерак Көнчыгыш.
18.00 Христиан программасы.
18.30 Яшь шундый биржа.
18.45 Парламент сәгате.
19.45 Көн дә бәйрәм.
20.25 "Санта Барбара".
21.15 Безнең бакча.
21.45 Криминаль хәбәрләр.
22.00 Бизнес һәм сәясәт.
23.20 Автомизгел.
23.25 Йолдызлар сөйли.
23.35 Концерт.

ПӘНҖЕШӘМБЕ

12 август

ТАТАРСТАН

7.00 "Чулпан".
17.30 Эфирда - компьютер информациясе.
17.40 "Мәктәп ерагы". Фильм.
19.00 Татарстан.
19.35 Хосусыйлаштыру: сораулар һәм җаваплар.
20.05 Әлли-бәлли-бәү.
20.20 Очрашулар.

ЭФИР

9.45 Телетекст.
10.00 Шәһәр.
10.15 "Мишень".
12.05, 17.30 Спутник телевидениесе.
17.00 Мультфильм.
19.00 Фантом.
19.45 Дөнья бүген.
20.10 "Баунти"дагы фетнә".

ОСТАНКИНО

6.00, 9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 21.00 Яңалыклар.
6.20 Иртәнге гимнастика.
6.30 Иртә.
8.45 Фирма гарантия бирә.
9.20 Һиндстан сәнгате.
9.50 "Мария".
10.35 "Чал кояш".
11.05 "Сары елга". 5 серия.
12.20 "Менә җәй дә җитте". Нәфис фильм.
13.25 Рус рәсем сәнгате.
13.55 "Спрут-3".
15.25 Телемикст.
16.10 Блокнот.
16.15 Мультфильм.
16.40 К.Дебюсси. Соната.
17.00 Епископ Василий.
17.10 Джем.
17.40 16га кадәр һәм өлкәнрәкләр.
19.00 "Мария".
19.45 Кинопанорама.
20.40 Тыныч йокы, нәниләр.
21.40 "Миллион".
22.10 "Апа". Нәфис фильм.

РОССИЯ

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 Хәбәрләр.
8.20 Хезмәт биржасы.
8.30 Эшлекле кешеләр заманы.
9.00 Иртәнге концерт.
9.15 Бизнес һәм сәясәт.
10.10 Мультфильм.
10.35 М.Мишин бенефисы.
11.50 "Санта Барбара".
12.40 "Сүнгән йолдыз"?
13.10 Тула көйләре.
13.40 Крестьян мәсьәләсе.
14.25 Ак карга.
15.10 Пианист Н.Петров.
15.40 Рус визасы.
16.15 Терминал.
16.45 Там-там яңалыклары.
17.00 Музыка классы.
17.30 Трансросэфир.
18.00 Кире адрес.
18.45 Парламент сәгате.
19.45 Көн дә бәйрәм.
20.25 "Санта Барбара".
21.15 Хроно.
21.45 Криминаль хәбәрләр.
22.00, 23.50 Тын йорт.
23.20 Автомизгел.
23.25 Йолдызлар сөйли.
23.35 Әйдәгез, ачыклык кертик.

ҖОМГА

13 август

ТАТАРСТАН

7.00 "Чулпан".
18.05 Мультфильм.
18.25 Концерт.
18.50 Ут һәм кешеләр.
19.00 Татарстан.
19.35 Видеоспорт.
19.45 Әлли-бәлли-бәү.
19.55 Җомга көн кич белән.
20.35 Ф.Галәвиева җырлый.
20.55 Р.Абязов җитәкчелегендәге оркестр уйный.

ЭФИР

10.00, 13.20, 17.30 Супер чэннел.
10.30 "Баунти"дагы фетнә".
17.00 Мультфильмнар.
19.20 Дөнья туристик күзлегеннән.
19.45 Шәһәр.
20.00 Телетекст.
20.15 "Кояш империясе". Нәфис фильм.
22.40 Шәһәр.

ОСТАНКИНО

6.00, 9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 21.00 Яңалыклар.
6.20 Иртәнге гимнастика.
6.30 Иртә.
8.45 Фирма гарантия бирә.
9.20 "Төш сатучы". Нәфис фильм.
10.50 О.Мандельштам.
11.10 Сәяхәтчеләр клубы.
12.20 Курчак спектакле.
13.25 Док.фильм.
13.55 "Тормыш вакыйклары".
15.25 Бридж.
15.50 Бизнес-класс.
16.05 "Рикки-тикки-тави".
17.20 Безнең музыкаль клуб.
18.20 "Останкино" телеканалы.
18.45 Кеше һәм закон.
19.15 03 вагоны.
19.45 Могҗизалар кыры.
20.40 Тыныч йокы, нәниләр.
21.40 Атна кичесе.
21.55 "Суини". 7 серия.
22.55 Максима.
23.20 Автошоу.
23.25 "Х" программасы.

РОССИЯ

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 Хәбәрләр.
8.20 Хезмәт биржасы.
8.30 Эшлекле кешеләр заманы.
9.00 Параллельләр.
9.15 Тын йорт.
10.10 Безнең бакча.
10.40 Хайваннар дөньясында.
11.40 Мультфильм.
11.50 "Санта Барбара".
12.40 М.Таничның алтын дискы.
13.40 Крестьян мәсьәләсе.
14.25 Телетеатр.
16.10 Док.фильм.
16.40 Там-там яңалыклары.
16.55 "Рост" студиясе.
17.25 Трансросэфир.
17.55 "Бурсык белән сөйләшкән малай". 2 серия.
18.45 Парламент сәгате.
19.45 Көн дә бәйрәм.
20.25 Н.Макарова һәм Р.Виктюк.
21.35 "Рок стилендәге трагедия". 1 серия.
23.20 Автомизгел.
23.25 Йолдызлар сөйли.
23.35 "Рок стилендәге трагедия". 2 серия.

ШИМБӘ

14 август

ТАТАРСТАН

7.00 "Чулпан".
17.35 "Ганди". 1 серия.
19.00 Татарстан.
19.30 Рәссам Ш.Шәйдуллин.
19.40 Якташлар.

ЭФИР

10.00 Грация.
10.30 Шәһәр.
10.45 "Кояш империясе".
13.05 Супер чэннел.
19.00 "Сау бул, блюз". Нәфис фильм.

ОСТАНКИНО

7.00, 15.00, 21.00 Яңалыклар.
7.25 Иртәнге гимнастика.
7.35 Эшлекле кешенең шимбә иртәсе.
8.20 Спорт-шанс.
8.50 Марафон-15.
9.15 Эльдорадо.
9.45 Шимбә автографы.
10.15 Экономик күзәтү.
10.30 Медицина синең өчен.
11.10 Музаларга хезмәт ыгы-зыгыны яратмый.
11.40 Л.Енгибаров исемендәге конкурс.
12.30 Хакимият чагылышлары.
12.45 "Неистовый" турында хикәят". Нәфис фильм.
14.30 Алма-Ата шәһәреннән тапшыру.
15.25 Мультфильм.
15.50 Үзәк экспресс.
16.20 П.Аедоницкийның иҗат кичәсе.
17.30 Җиңел атлетика.
18.30 Акча һәм сәясәт.
19.00 Сезнең өчен очрашу.
19.50 "Хьюстон рыцарьлары". 7 серия.
20.40 Тыныч йокы, нәниләр.
21.40 "Зәңгәр һәм соры". 7 серия.
22.30 Канкан.
22.50 Аншлаг.

РОССИЯ

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 Хәбәрләр.
8.25 Дөньяга үз карашың.
9.00 Битлек-шоу.
9.30 Билгесез галәм.
10.00 "Рост" студиясе.
10.30 Пилигрим.
11.15 Ничек яшәрбез?
12.00 "Эзтабарлар". Нәфис фильм.
13.30 Мультфильм.
13.40 Крестьян мәсьәләсе.
14.20 В.Каверин.
15.05 Күңел ачу викторинасы.
15.50 Музыкаль фестиваль.
16.50 Өч Гайдар.
17.20 Чикләрне белмәүче футбол.
18.15 Фильм-премьер.
18.30 Театраль сәфәр.
19.15 Сабый теле белән.
19.45 Көн дә бәйрәм.
20.25 "Чакыр мине якты еракка". Нәфис фильм.
22.00 Утә яшерен.
23.20 Автомизгел.
23.25 Йолдызлар сөйли.
23.35 "А" программасы.

ЯКШӘМБЕ

15 август

ТАТАРСТАН

7.00 "Чулпан".
18.00 "Ганди". 2 серия.
19.25 Концерт.
19.55 Әлли-бәлли-бәү.
20.05 Телесеанс.
21.05 Җыен-93.

ЭФИР

10.00, 12.45 Спутник телевидениесе.
10.30 "Сау бул, блюз".
18.05 Мультяшкалар музее.
18.25 "Бию өермәсендә".
19.25 Сәүдә каруселе.
19.55 Телетекст.
20.40 "Аэроплан-1". Нәфис фильм.

ОСТАНКИНО

7.00, 15.00, 18.45 Яңалыклар.
7.20 Иртәнге гимнастика.
7.30 Автошоу.
7.45 Технодром.
8.00 Көчле рух сәгате.
9.00 Үзәк.
9.30 Иртән иртүк.
10.00 Бар да өйдә чакта.
10.30 Спортлото.
10.45 Иртәнге йолдыз.
11.35 Хәрби ревю.
12.05 Һәм тагын халыкара яшьләр...
12.35 Детектив-лэнд.
13.25 Док.фильм.
14.00 Мультфильм.
14.10 Су асты одиссеясы.
15.20 Туры эфирда әңгәмә.
16.00 Сәяхәтчеләр клубы.
16.50 Һөнәрләрнең тере агачы.
16.55 Мультфильм.
17.45 Панорама.
18.25 Арутюн Акопян.
19.00 Халык иҗаты.
19.50 "Шакти". 1, 2 серияләр.
22.00 Нәтиҗәләр.
22.45 Спорт.
23.00 Җиңел атлетика.

РОССИЯ

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 Хәбәрләр.
8.25 Док.фильм.
8.45 Мультфильм.
9.00 Фольклор.
9.30 Хәерле иртә.
10.00 Музыкаль класс.
10.30 03 программасы.
11.00 Армия турында тапшыру.
11.30 "Кече Европа"дан репортажлар.
12.00 В.Шукшин.
13.00 Мультфильм.
13.10 Кемнәр алар "яңа урыслар"?
13.40 Крестьян мәсьәләсе.
14.20 Юнып ташлап булмый.
14.35 Дөньяны хәзер коткарыйк.
15.05 Ак карга.
15.50 Автоузышлар.
17.55 Диснейның тылсымлы дөньясы.
18.45 Тапшырулар тартмасы.
19.00 Җиңел атлетика.
19.45 Көн дә бәйрәм.
20.25 "Юка боз". Нәфис фильм.
22.10 Ксюша янында.
22.40 В.Познер Америкасы.
23.20 Автомизгел.
23.30 Спорт каруселе.
23.35 Джентельмен-шоу.



Укытучы кыз тактага акбур белән алмага охшатырга тырышып сурәт ясый һәм укучыларга сорау бирә:

- Балалар, бу нәрсә?

Гали бик сөенеп чәчрәп тора:

- Күт!

Бөтенесе пырхылдап көлеп җибәрә, ә укытучы кыз елый-елый директор янына йөгерә.

- Алар... анда... тактада... күт...

Директор атылып класска килеп керә, тактага күз сала һәм кычкырып җибәрә:

- Кайсыгыз ясады тактага бу күтне?

* * *

Гид туристларны Париж буйлап йөртә.

- Сул якта Эйфель манарасы, - ди ул, - ә манара астында 100 франк торучы хатын-кызлар. Менә Елисей кырлары. Сүз уңаеннан, биредә хатын-кызларның бәясе 200 франк. Без хәзер Сена буенда. Әнә теге хатыннар 300 франк тора.

- Гафу итегез, месье, - ди туристларның берсе, - ә сездә инсафлы хатын-кызлар бармы?

- Әлбәттә бар, ләкин аларның бәяләре бик кыйммәт.



Сугышчан рухта иҗат ителгән бу костюм Парижда 1993 елның язгы-җәйге кием үрнәкләре белән бергә күрсәтелде. Кайбер тәвәккәл ханымнар, әлбәттә, аны үз итәрләр.

* * *

Бу очракта, мөгаен, мода өчен "корбан" булу турында әйтү урынлырактыр. Мода өчен



Ева Сальван хатын-кызның иң төп бизәге булган чәчен кырдырып алдырырга да курыкмаган хәтта.

Рәсемдә: манекен Ева Сальван "Шанель" фирмасы костюмын күрсәтә.

ТАСС фотолары.



Русия кайчан туачак?

...2003 нче ел - Балык чорыннан Сукояр чорына күчү елы. Ә Русиянең туган чоры - Сукояр чоры имеш. Менә шуңа күрә дә Русиянең чынлап торып аякка баса башлавы, ягъни мәсәлән яңадан тууы, 2003 нче елда булыр дип фараз ителә.

Кем-кемне үтерә?

С.-Петербург, Мәскәү, Воронеж һәм Харьков шәһәрләрендә үз-үзләрен үтерергә теләүчеләр клублары ачылган. Дөрес, "клабмэннарның" тормыш белән исәп-хисапларын ничек өзәргә җыенулары мәгълүм түгел-түгелен, әллә алар берсен-берсе үтерергә җыенадырмы, әллә башкачадырмы...

Йолдыз - әти булачак

Кайбер чыганаклардан килеп ирешкән хәбәрләргә караганда, Америка эстрадасының гына түгел, дөнья эстрадасының суперйолдызы Майкл Джексон ике яшьлек ятимә корея кызчыгын тәрбиягә алырга карар иткән.

Чүплек - бай урын

Беларусь республикасы туристлары Германия чүплекләрен штурмлыйлар һәм аннан өйләренә иске дубленка, телевизор, видеомагнитофон ише нәрсәләр ташыйлар, имеш. Таможня чүплектән җыелган әйберләр өчен пошлина да алмый ди.

...Аз иде шул

Атом энергиясе эшләп чыгару белән шөгыльләнүче фин концерны Русиягә яңадан радиоактив калдыклар экспортлый башлаячак. Русия властьларының моңа рөхсәте бар.

!!!

*** Сез беләсезме? * Сез беләсезме? * Сез беләсезме? * Сез беләсезме?**

ТӨСЛӘР... ДӘВАЛЫЙ

Курган докторы Геннадий Демидов гомеопат түгел, әмма аның Халыкара конгресста әйткән хәбәре сенсация иде: төсләр ярдәмендә дәвалану теләсә нинди даруга караганда да нәтиҗәлерәк. "Аллопатик (рәсми) медицина дөрес булмаган теория буенча эш итә, һәм шуннан ялгыш практика барлыкка килә, - ди Геннадий Иванович - Аллопатлар кешене бербөтен итеп түгел, ә төрле өлешләрне тәшкил итүче җыелма рәвешендә дәвалыйлар, ягъни бавырны аерым, үпкәне аерым, йөрәкне - аерым..."

1981 елдан ул кешене төсләр ярдәмендә дәвалау белән мавыга башлый. Ул төрле илләрнең һәм халыкларның меңьеллык тәҗрибәсен җыйнап берләштерә. Шулар нәтиҗәсендә "төс терапиясе" дигән китабы барлыкка килә. Ә тестны Демидов ЭВМ ярдәмендә үзе төзи. Аның бу материаллары әлегә матбугатта чыкканы юк. Геннадий Ивановичның көндәлек тормышта үз-үзеңне дәваларга мөмкин булган өйрәнүләрен без сезгә дә тәкъдим итәбез, хөрмәтле укучыларыбыз.

Кеше организмына төсләр ничек тәэсир итә соң?

Кызыл төс

Ул стимуляцияне яхшырту өстенә, умыртка баганасындагы сыеклыкны һәм нерв системасын ярсындыра, гемоглобин төзелешен үстерергә булыша, бавырга энергия бирә, мускуллар һәм баш миенең сул ярымшарына яхшы тәэсир итә.

[illegible], кан бозылуны, күкрәк бакасын, эч катуны, эндокрин системасын, апатияне, меланхолияне, паралич, үпкә авыруын, туберкулезны дәвалый. Ә менә югары темпераментлы эмоциональ (хисчән) кешеләр өчен зарарлы. Буылу, югары артериаль кан басымы, ялкынсыну, неврит авырулы кешеләргә дә ярамый бу төс. Шулай ук кызылны ачык җирән төстәге кешеләр дә куралмый.

Сары

Нервларга, аяк-кулларга, мускулларга, үт куыгына файдалы. Диабет, ашказаны авыруларын, экзема, геморрой, ревматизм, бөер, бавыр, талакны дәвалый. Галлюцинацияләр белән саташучылар, эч китү, бизгәк тоту, невралгия, йөрәк кагу кебек авыру белән интегүчеләр өчен зарарлы.

Кызылсары

Җылылык китерә, калкансыман бизгә стимуляция бирә, үпкәне ныгыта, имезүче аналарның сөтен арттыруга булыша, талак һәм ашказаны асты бизенең эшчәнлеген яхшырта. Астма, ревматизм, туңу, үт куыгына таш җыйналу, подагра, бөер; бавырны дәвалый.

Яшел

Мускулларны ныгыта, сөякләргә файдалы, кан юлларындагы киеренкелекне бетерә, аларга салкынлык бирә, йомшарта, тынычландыра. Кан басымын төшерә, җылылык тоярга булыша, йокысызлыктан, арганлыктан яхшы, яшәртә, җенси эшчәнлекне җайларга булыша, дезинфекция ясый. Яшел - В витамины төсе, яшьлек, үсеш, өмет, яңа тормыш, энергия бирүче төс. Шулай ук көнчеллек, шикчеллек тә тудыра. Астманы, бизгәкне, йөрәкне, бавырны, геморрой, җәрәхәтләрне, йокысызлыкны дәвалый.

Зәңгәр

Пеләшләнүдән дәва бирә (баш түбәсенә көн саен 15 минут зәңгәр төстәге әйбер куярга), шешенү, пешү, күз авырулары (көн саен ярты сәгать зәңгәргә карарга), җил чәчәге, холера, эч китү, дизентерия, зоб, баш авырту, йокысызлык, сары, корчаңгы, скарлатина, теш, ашказаны һәм уникеилле эчәк, ютәл авыруларыннан, косудан, авыртулы күремнән файдалы. Паралич, ревматизм, тахикардия, мускуллар кысылудан зарарлы.

Шәмәхә

Сидек куыгы, сөяк, бөер, тән тиресе, менингит, күзән җыеру, ревматизмнан яхшы.

Ультрашәмәхә

Зоб, рахит, җәрәхәтләр, йөрәк, үпкә өчен файдалы.

Төсләр ярдәмендә дәваланып бетәргә мөмкин дип уйламагыз, алар - санап үтелгән авыруларны дәвалауда булышучылар.

Әгәр ябыгасыгыз килсә:

кызыл нурларга бай ризык ашарга тырышыгыз: чөгендер, кәбестә, чия, баклажан, суган, борыч, редиска, каен җиләге, помидор, карбыз. Көнгә 2 мәртәбә тозы чыгынкы су эчегез. Аны башта 2 сәгатькә кояш төшкән урында тотарга кирәк. Әлбәттә, су салынган савыт кызыл төстә булырга тиеш.

Әгәр тазарасыгыз килсә:

зәңгәр нурларга бай ризык ашагыз: слива, виноград, груша, сельдерей, пастернак, бәрәңге, балык, тавык һәм бозау ите. Зәңгәр савытка салып тотылган су эчегез.

Доктор Геннадий Демидов авыруларны әнә шулай дәвалый. Һәм ул бик зур файда бирә.

Йолдыз диетасы

Бу диета Һиндстанда эшләнгән. Кем кайсы йолдызлык астында туган булуга карап, аңа нинди ризыклар ашарга кирәклеген белергә мөмкин.

Сукоярга зәңгәр һәм ак төс җитми. Әгәр көндәлек ризыгында җиләк-җимеш, яшелчә: виноград, груша, кавын, сельдерей, бәрәңге, балык, тавык, бозау ите булса, хезмәткә сәләте әйбәт була.

Балыкка яшел һәм ак төстәге ризыклар - тамыразыклар, тропик җиләк-җимеш, яшелчә, балык, тавык, бозау ите, йомырка.

Кучкар - кызыл төстәге ризыклар - борыч, җиләк, помидор, редиска, карбыз, кәбестә, кызыл ит.

Үгезбозауга сары нурлар тансык, С, А витамины күбрәк кирәк: кишер, кавын, шалкан. Ул күз авыруларына бирешүчән.

Игезәкләргә сары һәм пурпур төс якын.

Кысла ак һәм яшел нурларга мохтаҗ: Кыяр, эремчек, кавынны күбрәк ашау мөһим.

Арысланга кызылсары һәм сары нурлар, С витамины җитми: җиләк-җимеш, карбыз, кабак, эремчек ашарга кирәк. Алар стрессларны авыр кичерәләр.

Кыз шәмәхә һәм алтын төсенә мохтаҗ. Алар калийга бай ризык ашарга тиеш.

Үлчәү алтын һәм кура җиләге төсеннән мәхрүм. Тамыразыклар һәм ит ашарга кирәк.

Чаянга кызыл һәм үт төсе җитми. Күбрәк ит ашарга һәм күп итеп сыеклык эчәргә кирәк.

Укчыга кызыл һәм алтын нурлар аз бирелгән. Аның ферментлары аз, пешеп чыкмаган ризыкларны яратып ашаса әйбәт булачак.

Кәҗәмөгез караңгы яшел нурлар җитмәүдән интегә. Аңа шундый төстәге һәм төрле диңгез ризыклары кирәк.

"Планетаны яңарту"
Халыкара Ассоциациясе вице-президенты
халык табибы
Рәфыйк МИННЕКӘЕВ

Чаллыда сәламәтләндерү сеанслары үткәрә. Экстрасенс бозыклыктан, полип, ангина, шикәр диабеты, гайморит, башлангыч стадиядәге лейкоз, умыртка сөяге сыну, баш мие травмаларын дәвалый, кан әйләнешен, ашказаны-эчәк системасы эшчәнлеген торгыза, бавыр һәм бөерләрдән ташны төшерә.

Дәвалау сеанслары ГЭС поселогындагы "Огонек" мәдәният йортында 13-17 август көннәрендә 10,13 һәм 18 сәгатьләрдә башлана.

ТЯ

Баш мөхәррир урынбасары
Миңназыйм СӘФӘРОВ
(53-07-52)

ЯЗЫГЫЗ:
420066, Казан, Декабристлар урамы,2.
"Татарстан яшьләре"

ШАЛТЫРАТЫГЫЗ:
53-07-52 - баш мөхәррир урынбасары
53-07-50 - җаваплы сәркатип, реклама
53-07-58 - хатлар бүлеге
53-07-54 - сәяси тормыш һәм тәрҗемә, фән һәм мәгариф
53-07-56 - мәдәният-сәнгать
53-07-52 - табигать, авыл тормышы

"Татарстан яшьләре"н гамәлгә куючылар - Татарстан Республикасының Яшьләр оешмалары советы, Татарстан Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы, редакциянең хезмәт коллективы.

Газета Татарстан республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 268-нче номерлы таныклык белән теркәлде.

"Т.Я" сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга

Редакциягә килгән материаллар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

Реклама һәм белдерүләрдәге мәгълүматларның дөреслеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы.

Редакциянең исәп-хисап счеты:
Р/с 700161998/700751 ВКАБ РКЦ ГЦБ г.Казани, МФО 265005
Индекс - 54121
Тираж - 203620

Татарстан газета-журналлар басмаханәсе. Газета басылуга кул кую графиК буенча 18 сәгатьтә. Бу санга 14 сәгатьтә кул куелды. Заказ 6127